академия
ПРОСВЕЩЕНИЕ

# ИССЛЕДОВАНИЕ ПРЕДМЕТНЫХ И МЕТОДИЧЕСКИХ КОМПЕТЕНЦИЙ УЧИТЕЛЕЙ

**Демонстрационный вариант диагностической работы по предметной области «Родной язык и родная литература (татарский язык и литература)»**

2018 г.

Настоящий демонстрационный вариант диагностической работы предназначен для участников исследования предметных и методических компетенций учителей по татарскому языку и литературе. Он дает возможность получить представление о структуре диагностической работы, количестве заданий, форме заданий, уровнях сложности заданий и критериях оценки выполнения заданий.

**Инструкция по выполнению работы**

На выполнение экзаменационной работы отводится 3 часа 20 минут (200 минут). Работа состоит из 2 разделов.

Раздел «Предметная компетентность» включает 15 тестовых заданий (8 по татарскому языку и 7 по татарской литературе). Раздел «Методическая компетентность» включает 3 задания по методике преподавания татарского языка и 3 по методике преподавания татарской литературы разной степени сложности.

В первую тестовую часть включены задания закрытого типа с единичным или множественным выбором правильных вариантов ответов, задания на соответствие, установление последовательности и задания открытой формы с кратким ответом. За верный ответ на каждое из заданий ставится один балл.

Во вторую часть включены методические педагогические задачи, предполагающие различное соотношение репродуктивной и творческой деятельности.

Первая задача преимущественно ориентирована на знание задач, принципов методики изучения того или иного уровня языка или развития речи, предполагает анализ предложенного материала и комментирование того или иного тезиса, приведение раскрывающих тезис примеров, квалификационные умения. Соотношение репродукции и поисковой деятельности примерно 70% : 30%.

Вторая задача ориентирована преимущественно на выявление сущности и причин ошибок, затруднений обучающихся, на корректировку дидактического материала и/или методики работы с ним. Соотношение репродуктивной и поисковой деятельности примерно 30% : 70%.

Третья задача предполагает моделирование элементов учебного процесса, поиск приемов предупреждения и преодоления затруднений обучающихся разного уровня обученности и обучаемости (в том числе с ОВЗ), с различными индивидуальными особенностями (учет межполушарной асимметрии, ведущей репрезентативной системы: аудиальной, визуальной, кинестетической), использования современных технологий и средств обучения для повышения эффективности обучения. Соотношение репродуктивной и поисковой деятельности примерно 15% : 85%.

Задания по методике преподавания литературы, составленные с учетом требований профессионального стандарта «Педагог», которые позволяют оценить степень сформированности общепедагогических и предметных компетенций. Выполняя каждое из предложенных заданий, аттестуемый педагог имеет возможность продемонстрировать уровень владения основными знаниями, умениями и навыками.

Выполняя задание № 1, аттестуемый должен продемонстрировать не только знание предмета (понимание специфики художественного слова и литературы как особого вида

искусства, основные теоретико-литературные знания), умение планировать учебное занятие, но и понимание принципов проблемного обучения, владение формами и методами последнего.

При выполнении задания № 2 необходимо использовать не только знание принципов и методов проблемного обучения, но и владение методами убеждения и аргументации своей позиции, умение устанавливать контакт с обучающимися в рамках учебного занятия, реализовывать профессиональные действия, способствующие формированию мотивации к обучению.

Задание № 3 предполагает демонстрацию умения планировать и организовывать учебные занятия в соответствие с принципами проблемного обучения, знание основ методики обучения литературе и принципов деятельностного подхода, навыки планирования и осуществления учебного процесса в соответствие с основной общеобразовательной программой.

Внимательно читайте формулировки заданий.

Желаем успеха!

**Татар теле һәм әдәбият укытучыларының предмет һәм методик компетенциясен бәяләү өчен бирелгән диагностик эшнең демонстратив варианты**

Диагностик эшнең әлеге демонстратив варианты татар теле һәм әдәбияты буенча укытучыларның предмет һәм методик компетенциясен тикшерү өчен тәкъдим ителә. Ул диагностика эшенең төзелеше, биремнәр саны, формасы, катлаулылык дәрәҗәсе һәм бәяләү критерияләре турында күзаллау тудырырга мөмкинлек бирә.

Эш үтәү өчен инструкция

Имтихан эше ике бүлектән тора һәм башкару өчен 3 сәгать 20 минут (200 минут) вакыт бирелә.

«Предмет компетентлыгы» бүлеге 15 тест биремен үз эченә ала (татар теленнән 8, әдәбияттан 7). «Методик компетентлык» исә татар телен һәм әдәбиятны укыту методикалары буенча төрле дәрәҗә катлаулылыктагы 3әр биремнән тора.

Беренче тест өлеше бер яки берничә дөрес җавап вариантын сайлап ала торган, туры килүгә, эзлеклелеккә корылган ябык типтагы һәм кыска җаваплы ачык формадагы биремнәрне үз эченә ала. Һәр дөрес җавапка бер балл куела.

Икенче өлешкә методика өлкәсенә караган биремнәр керә. Алар репродуктив һәм иҗади эшчәнлекне күз алдында тота.

Беренче мәсьәләдә укытучының телне яки сөйләм төзелешен теге яки бу дәрәҗәдә өйрәнү методикасы принципларын белүен, бирелгән материалга анализ һәм теге яки бу тезисны аңлатуын, квалификацион осталыгын тикшерү максаты куела. Репродуктив һәм эзләнү характердагы эшчәнлек якынча 70%:30% чагыштырмасында.

Икенче мәсьәлә хаталарның нигезен һәм сәбәпләрен, укучыларның материалны үзләштерүдә туган кыенлыкларын ачуга, дидактик материалны дөресләү һәм/яки алар белән эш методикасын сайлый белү осталыгын ачыклауга юнәлдерелгән. Репродуктив һәм эзләнү характердагы эшчәнлек якынча 30%:70% чагыштырмасында.

Өченче мәсьәлә уку процессы элементларын модельләштерүне, белем дәрәҗәләре, белемнәрне үзләштерү мөмкинлекләре төрле булган (аудиаль, визуаль, кинестетик) укучыларда (шул исәптән сәламәтлекләре чикле балаларда) авырлык тудырган очракларны искәртүне, белем бирүнең нәтиҗәлелеген арттыру өчен заманча технологияләр һәм чаралар куллануны күздә тота. Репродуктив һәм эзләнү характердагы эшчәнлек якынча 15%:85% чагыштырмасында.

«Педагог» профессиональ стандартлары таләпләрен күздә тотып төзелгән әдәбиятны укыту методикасы биремнәре гомумпедагогик һәм предмет компетенцияләре формалашу дәрәҗәсенә бәя бирә. Аттестация узучы педагог, бирелгән биремнәрнең һәрберсен үтәп, төп белемнәргә, осталык һәм күнекмәләргә ия булуын чагылдыра алачак. Укытучы, беренче биремне үтәп, предмет буенча гына белемнәрен түгел, ә проблемалы укыту принципларын аңлавын, аның формалары һәм алымнары белән эш итә белүен дә күрсәтә.

Икенче биремне үтәгәндә исә, укытучы проблемалы укытуның алымнарын һәм принципларын белүен генә түгел, ә үз позициясен аңлату һәм ышандыра алу методларына ия булуын, дәрестә укучы белән элемтә урнаштыра, белем алуга этәргеч тудыра ала торган профессиональ эшне тормышка ашыра белүен кулланырга тиеш.

Өченче бирем укытучының проблемалы укыту принципларына туры китереп укуны оештыра һәм планлаштыра алуын күрсәтүне, әдәбият укыту методикасы нигезләрен һәм эшчәнлекле якын килү принципларын, уку процессын төп белем бирү программасына нигезләнеп тормышка ашыру һәм планлаштыру күнекмәләренә ия булуын чагылдыруны күздә тота.

Биремнәрне игътибар белән укыгыз!

Уңышлар телибез!

## Бүлек 1. Предмет компетенциясе

## Бүлек 1.1. Татар теле

**1. Определите группу щелевых согласных**

**Өрелмәле тартыклар төркемен билгеләгез**

□ [т], [г], [п]

□ [ж], [һ], [с]

□ [к], [ң], [х]

□ [м], [р], [л]

**2. Установите соответсвие**

**Тәңгәллек урнаштырыгыз**

| | |
|---|---|
| 1. Омонимнар | А. Яшь – карт |
| 2. Синонимнар | Ә. (Печән) чаба – (тиз) чаба |
| 3. Антонимнар | Б. Сөйкемле - мөлаем |
| 4. Паронимнар | В. Болытлы (көн) - кояшлы (көн) |
| | Г. Тугры - туры |
| | Д. Орфоэпия – дөрес әйтелеш |

**3. Установите соответствие способа словообразования и слова.**

**Сүз ясалышы ысулы һәм сүз арасында тәңгәллекне табыгыз**

| | |
|---|---|
| 1. Кушымчалау | А. кайнар |
| 2. Сүзләр кушылу | Ә. терекөмеш |
| 3. Конверсия | Б. татарча |
| 4. Сүзтезмәләр лексикалашу юлы | В. озынборын |
| | Г. хатын-кыз |

**4. Укажите группу состоявшую из самостоятельных частей речи**

**Мөстәкыйль сүзләр генә булган төркемне күрсәтегез**

□ каен, зур, малай, бугай, әллә, ал

□ турында, иң, чынлап, җырлап, әле

□ кышкы, җыр, мин, ун, зур

□ кием, әлбәттә, көчле, мөгаен, дөрес

□ алтын, нур, мени, әле, урап

**5. Определите разновидность простого предложения.**

**Бирелгән гади җөмләнең төрен билгеләгез**

Диңгез суын эчеп булмый.

□ үтәүчесез җөмлә

□ билгеле үтәүчеле фигыль җөмлә

□ гомуми үтәүчеле фигыль җөмлә

□ билгесез үтәүчеле фигыль җөмлә

**6. Укажите признак научного стиля**

**Фәнни стильгә хас булган билгене күрсәтегез**

□ фразеологик берәмлекләрне күп куллану

□ җөмләләрдә гади сөйләм сүзләре күп булу

□ махсус терминнар һәм формулалар күп куллану

□ сурәтләү чаралары куллану

**7. Нормы литературного языка -**

**Әдәби тел –**

□ гомумхалык сөйләм теленең тел осталары тарафыннан эшкәртелгән, нормага салынган формасы;

□ билгеле бер телдә сөйләшүче кешеләрнең фикерне аңлаешлы итеп һәм гасырлар буена урнашып килгән таләпләрне бозмыйча, төгәл итеп сөйләү формасы;

□ язганда һәм сөйләгәндә алга куелган максатка ярашлы рәвештә тел-сурәтләү чараларыннан файдалану үзенчәлекләре.

□ төрле төбәкләрдә яшәп, төрле диалектларда сөйләшүче бер милләт кешеләре үзара аңлаша алырлык итеп эшкәртелгән һәм фәнни нормаларга салынган тел.

**8. Определите слово, в котором наблюдается несоответствие между произношением и написанием**

**Әйтелеше белән язылышы туры килмәгән сүзне билгеләгез**

□ китабы

□ болынын

□ үсемлек

□ чәчәк

## 1.2. Татарская литература.

## Татар әдәбияты

**9. Основные признаки драмы как рода литературы**

**Әдәби төр буларак драмага хас билгене күрсәтегез:**

1. вакыйга бер хикәяләүче аша гына сөйләнә
2. монолог һәм диалогларга корыла, искәрмәләр (ремаркалар) белән төзелә
3. лирик герой кичерешләре алгы планга куела
4. язучы вакыйгага һәм геройларга үз мөнәсәбәтен белдереп сурәтли

Җавап________________

**10. Установите соответствие между родами литературы и жанрами.**

**Һәр жанрны үзе караган әдәби төр белән парлаштырыгыз:**

| | |
|---|---|
| 1.Эпик | А. трагедия |
| 2. Драма | Ә.баллада |
| 3. Лирик | Б. хикәя |
| 4.Лиро-эпик | В. шигырь |

Җавап_______________________________________

**11. Выбирите литературные направления.**

**Иҗат юнәлешләрен аерып күрсәтегез:**

1. Гуманизм. 2. Футуризм. 3. Романтизм. 4. Мәхәббәт лирикасы. 5.Модернизм. 6. Реализм.

Җавап______________________________________

**12. Произведение Г.Тукая “Исемдә калганнар”:**

**Г. Тукайның “Исемдә калганнар” әсәре:**

1. тарихи роман
2. автобиографик повесть
3. сатирик поэма
4. фантастик хикәя

Җавап______________________________________

**13. Установите соответствие между терминами и их определениями.**

**Төшенчәләр һәм аңлатмалар арасында дөрес тәңгәллек урнаштырыгыз**

| | |
|---|---|
| 1. Сюжет | А. әсәр өлешләренең урнашу тәртибе |
| 2. Композиция | Ә. конфликтларның башлану ноктасы |
| 3. Төенләнеш | Б. вакыйга-хәлләр яки кеше холкы-характерының үсү-үзгәрү тарихы |

Җавап________________________________________

**14. Определите памятник древней общетюркской литературы.**

**Борынгы гомумтөрки әдәбиятка караган истәлекне билгеләгез**

1. С. Сараи "Гөлстан бит-төрки"
2. "Юрау китабы"
3. Хисам Кятиб "Җөмҗөмә солтан"
4. "Идегәй" дастаны

Җавап________________________________________

**15. Укажите произведение, которое относится к пейзажной лирике.**

**Пейзаж лирикасына караган әсәрне күрсәтегез**

1. Г. Тукай "Җәйге таң хатирәсе"
2. Һ. Такташ "Мокамай"
3. М. Җәлил "Җырларым"
4. Р. Харис "Ак сөлге"

Җавап________________________________________

## Бүлек 2. Методик компетенция

### Бүлек 2.1. Татар телен укыту методикасы

**16 (1). Один из важнейших принципов методики изучения грамматики – «изучение форм глагола с точки зрения семантики». Разъясните сущность этого принципа и приведите примеры.**

**Татар теле грамматикасын укыту методикасының мөһим мәсьәләләренең берсе – фигыль формасын аның эчтәлегенә бәйле рәвештә өйрәтү. Әлеге принципның асылын аңлатыгыз, мисаллар китерегез.**

**17 (2). Введение новых знаний учитель провел следующим образом: “В одном из ниже приведенных предложений выделенный глагол не имеет семантику желательного наклонения глагола. Найдите и преобразуйте в форму желательного наклонения”.**

**Яңа белем бирүдә яки аны ныгытуда түбәндәге бирем кулланыла ала: “Түбәндә китерелгән җөмләләрнең берсендә аерып куелган фигыль теләк мәгънәсен белдерми. Шул очракны табыгыз һәм теләк мәгънәсен белдерә торган итеп үзгәртегез”.**

Җөмләләр:

1) Кемнән дә булса сорашып **беләсем килде**.

2) Яхшыга **булсын**, ходаем!

**3) Еларга, еларга иде** хәзер, күз яшьләрең дәрья булып бөтен хәсрәтеңне **алып китсен иде.**

4) Шул дәрьяда үзең дә йөзеп китеп, тыныч, кешесез **чыгыең**.

5) Тизрәк **кыймылдагыз,** машиналар **кузгалмасын.**

6) Эх, уйларны да, керләр кебек, ак иткәнче, пакъ иткәнче **чайкарга**!

Найдите правильный ответ и обоснуйте, укажите на типичные ошибки ученика при выполнении данного задания.

Дөрес җавапны әйтегез һәм дәлилләгез. Укучының әлеге биремне чишкәндә күзәтелә торган типик хаталары нинди?

18 (3). Как вы разъясните несоответствие между формой и семантикой глагола, проблемным методом, учитывая связанные с темой принципы методики изучения грамматики и разные типы восприятия, индивидуальные и возрастные особенности учеников, использовать элементы современных технологий и системно-деятельностный подход?

Татар теле грамматикасын укыту методикасына һәм принципларына нигезләнеп, заманча укыту технологияләрен һәм системалы-эшчәнлекле юнәлешне кулланып, укучыларның әзерлек дәрәҗәсен, индивидуаль һәм яшь үзенчәлекләрен истә тотып, сез татар телендә фигыль формасы белән эчтәлеге туры килмәгән очракны балаларга ничек аңлатырсыз?

**2.2 Әдәбиятны укыту методикасы**

Әдип, иманын барлагандай, һәр нәрсәне кабат күңеленнән кичерде: “Ык буйларының бу тирәсендә җир-суның, үсемлек һәм җәнлекләрнең шушы як табигатенә хас үзенчәлекләре сакланып калган. Мәгълүм булганча, бу төбәкнең ландшафты хакында рус язучысы Сергей Аксаков та игътибарга лаеклы истәлекләр язып калдырган. Шуларның һәммәсен искә алып, бу тирәне табигать һәйкәле итеп саклау турында хөкүмәт махсус карар чыгарды. Шулай булгач, кайбер кешеләрнең тугай белән чишмәләрне бозып ташлауларын берничек тә аклау мөмкин түгел. Гомер буе халык тормышында шатлыклы җыр булып яңгырап яшәгән көмештәй саф сулы чишмә ничек әле бүген генә, тормышлар җайга салынып килгәндә генә, кирәкмәс булып чыксын икән?! Һич тә аңлашылмый.

Язучы буларак минем вазифам – туган-үскәнякларның табигатенә карата менә шундый кансызлыкларны, салкын битарафлыкны, ваемсызлыкны фаш итү, халыкта табигатькә мәхәббәт уяту. Мин гаделлек өчен көрәшәм. Мин бу әсәремне хакыйкатьнең өстен чыгачагына ышанып, шуның белән рухланып язам. Әгәр дә шундый ышаныч канатландырып тормаса, минем язып утыруымның бер мәгънәсе дә калмас иде ...” (Г. Бәширов)

**19 (1) Какие из предложенных учителем вопросов носят проблемный характер?**
**Укытучы биргән сорауларның кайсысын проблемалы сорау дип саныйсыз:**

1. Отождествляется ли образ писателя с рассказчиком?
2. Какие символические образы использует автор?
3. Как вы считаете, имеет ли писатель задачи перед народом, какие?
4. Назовите автора произведения и его название.

1.Текстта язучы образы һәм хикәяләүче белән тәңгәл киләме?

2. Автор нинди символик образлар куллана?

3. Язучының халык алдындагы вазифасы нинди дип уйлыйсыз?

4. Әсәрнең авторын һәм исемен атагыз.

**20 (2)** На заданный учителем вопрос «Является ли охрана природы долгом каждого?» один из учеников ответил: «Нет, охрана природы не является нашим долгом, для этого имеются специальные организации». Многие с ним согласились. Что следует предпринять в этой ситуации учителю? Выберите из предложенных вариантов. Аргументировано объясните свою точку зрения.

1. Упрекнуть ученика в непонимании и оставить его точку зрения «без комментария».
2. Возмутиться и вступить в спор.
3. Предложить снова обратиться к тексту и внимательно его перечитать.
4. Развить возникшую ситуацию, сформулировав проблемную задачу.

**Укытучының: “Табигатьне саклау һәркемнең бурычы дип саныйсызмы? – дигән соравына бер укучы: “Юк, табигатьне саклау безнең бурыч түгел, аның өчен махсус оешмалар бар,” – дип җавап бирә. Укучыларның бер төркеме аның белән килешүен белдерә. Укытучы бу очракта ни эшли:**

1.Укучыны һәм теләктәшлек белдерүчеләрне бик каты кисәтә, алга таба бу фикерне исәпкә алмый гына дәресне дәвам итә.

2.Укучының хаксызлыгын бик күп мисаллар белән дәлилли, иптәшләреннән дә бу фикернең хата булуын дәлилләтә. Дәресен бу фикернең хата булуын раслауга багышлый.

3. Килеп туган каршылыклы фикердән проблемалы мәсьәлә тудырып аны уртага салып хәл итә һәм нәтиҗә ясыйлар.

**21 (3)** Для того, чтобы разрешить описанную в задании 2 ситуацию сформулируйте проблемный вопрос к тексту (или предложите вариант проблемной задачи), поиск ответа на который мог бы стать переломным моментом урока.

**Алда тасвирлаган ситуацияне хәл итү өчен проблемалы сорау тәкъдим итегез. Аның дәрес барышына тиешле юнәлеш бирерлек булуын дәлилләгез.**

**Диагностика эшен бәяләү системасы**

**Бүлек 1. Предмет компетенциясен бәяләү өчен биремнәр**

Һәрбер тулы дөрес җавап өчен бер балл куела.

| Бирем № | Дөрес җавап | Баллар |
|---|---|---|
| 1 | [ж], [һ], [с] | 1 |
| 2 | 1Ә, 2БД, 3АВ, 4Г | 1 |
| 3 | 1Б, 2ӘГ, 3А, 4В | 1 |
| 4 | кышкы, җыр, мин, ун, зур | 1 |
| 5 | гомуми үтәүчеле фигыль җөмлә | 1 |
| 6 | махсус терминнар һәм формулалар күп куллану | 1 |
| 7 | төрле төбәкләрдә яшәп, төрле диалектларда сөйләшүче бер милләт кешеләре үзара аңлаша алырлык итеп эшкәртелгән һәм фәнни нормаларга салынган тел | 1 |
| 8 | болынын | 1 |
| 9 | 2 | 1 |
| 10 | А 2; Ә4; Б1; В3; | 1 |
| 11 | 3.Романтизм, 5.Модернизм, 6.Реализм | 1 |
| 12 | 2 | 1 |
| 13 | 1Б, 3Ә, 2А. | 1 |
| 14 | 2 | 1 |
| 15 | 1 | 1 |
| | Барлыгы | 15 балл |

**Критерии оценивания заданий**
**для оценки методических компетенций по татарскому языку**

**Критерии оценивания задания 16**

| Критерий оценивания | Соответствие критерию | Баллы |
|---|---|---|
| Понимание принципов методики изучения грамматики, умение объяснить основы сложных грамматических явлений | Отсутствие ответа, неправильный ответ | 0 |
| | Раскрыт принцип методики изучения грамматики | 1 |
| Наличие правильно приведенного примера | Пример приведен неверно или отсутствует | 0 |
| | Пример приведен правильно | 1 |
| Наличие комментария к примеру | Комментарий отсутствует или неверный | 0 |
| | Приведен корректный комментарий | 1 |
| | Итого | 3 балла |

**Критерии оценивания задания 17**

| Критерий оценивания | Соответствие критерию | Баллы |
|---|---|---|
| Обнаружение лингвистической ошибки | Отсутствие ответа, не обнаружена или неверно | 0 |
| | Определена лингвистическая ошибка | 1 |
| Умение анализировать ошибки допущенные при выполнении заданий и владение методикой работы над ошибками | Не указываются типичные ошибки учащихся, либо они указаны неправильно | 0 |
| | Ошибки и методика над ошибками указаны правильно | 2 |
| Определение возможных ошибочных суждений учащихся вследствие однотипности представленного языкового материала | Не определены или определены неверно возможные ошибочные суждения учащихся вследствие однотипности представленного языкового материала | 0 |
| | Правильно определены возможные ошибочные суждения учащихся вследствие однотипности представленного языкового материала | 2 |
| | Итого | 5 баллов |

**Критерии оценивания задания 18**

| Критерий оценивания | Соответствие критерию | Баллы |
|---|---|---|
| Проблемный метод изучения материала | Отсутствие ответа, проблемный метод изучения материала отсутствует | 0 |
| | Предложен проблемный метод изучения материала | 1 |
| Учтены все необходимые принципы методики изучения грамматики, | Не реализованы значимые для изучения материала принципы методики изучения грамматики | 0 |
| | Реализованы не все значимые для изучения материала принципы методики изучения грамматики | 2 |
| Использована наглядность | Использована только вербальная наглядность (примеры слов) | 0 |
| | Использована визуальная и/ или кинестетическая наглядность, ИКТ | 2 |
| Прокомментирован учет индивидуальных и возрастных особенностей обучающихся | Не учтены индивидуальные особенности обучающихся | 0 |
| | Учитываются индивидуальные и возрастные особенности и уровень развития (ОВЗ) обучающихся | 2 |
| | Итого | 7 баллов |

**Критерии оценивания задания**
**для оценки методических компетенций по литературе**

Критерии оценивания заданий 19-21

| Критерий оценивания | Соответствие критерию | Баллы |
|---|---|---|
| 19 (1) Понимание принципов проблемного обучения и владение его формами и методами | Правильный вариант ответа – 3<br>Выделены все признаки проблемного вопроса.<br>1. Многовариантность ответов.<br>2. Сложность. Требует мыслительной аналитической деятельности, неоднократного обращения к тексту.<br>3. Доступность. Ответ может быть найден благодаря работе над текстом<br>4. Интерес. Вопрос должен провоцировать на размышление, вызывать желание найти на него ответ.<br>5. Ёмкость. Вопрос должен охватывать либо всё произведение, либо ег суть | 3 |
| | Выделены не все признаки проблемного вопроса, только основные /есть ошибки в выделении признаков/вопрос выбран верно, но ответ не обоснован | 2 |
| | Не выделены признаки проблемного вопроса и неверно указан правильный ответ | 0 |
| 20 (2)<br>Владение методами убеждения и аргументации своей позиции, умение устанавливать контакт с обучающимися в рамках учебного занятия, реализовывать | Правильный ответ -№3. Имеется обоснование, что с методической и общепедагогической точки зрения предпочтительным является этот вариант, решение возникшей проблемной ситуации путем сравнительного анализа двух точек зрения, которые должны аргументироваться с опорой на текст произведения, историко-культурные знания и личный опыт обучающихся. | 5 |
| | Выбран верный вариант ответа, но не указаны аргументы, которые позволяют оценить знание | 3 |

| | | |
|---|---|---|
| профессиональные действия, способствующие формированию мотивации к обучению. | специфики методов проблемного обучения. Выбран неверный вариант ответа, но есть обоснование – предложен свой вариант сценария проблемной ситуации | |
| | Выбран неверный вариант ответа и нет обоснования. | 0 |
| 21 (3)<br>Умение планировать и организовывать учебные занятия в соответствие с принципами проблемного обучения | Сформулирован проблемный вопрос к тексту, который соответствует основным признакам проблемного вопроса или предложен вариант проблемной задачи, указано обоснование, каким образом этот вопрос или ситуация могли бы стать переломным моментом урока. | 7 |
| | Сформулирован проблемный вопрос, но нет обоснования выбора. | 3 |
| | Не сформулирован проблемный вопрос, не предложена проблемная задача . | 0 |
| Итого | | 15 баллов |

**Бүлек 2. Методик компетенцияләрне бәяләү өчен биремнәр**

**Татар теленнән методик компетенцияләрне билгеләү өчен тәкъдим ителгән биремнәрнең бәяләү критерийлары**

**16 биремне бәяләү критерийлары**

| Бәяләү критерийлары | Критерийга туры килү | Баллар |
|---|---|---|
| Грамматиканы өйрәтү методикасы принципларын аңлау, катлаулы грамматик очракларның асылын аңлата алу | Җавап юк яки хаталы җавап | 0 |
| | Дөрес, тулы җавап | 1 |
| Дөрес мисаллар китерү | Мисал юк яки хаталы мисал | 0 |
| | Дөрес мисал китерелә | 1 |
| Мисалларга комментарийлар бирү | Мисалларга комментарийлар юк яки дөрес түгел | 0 |
| | Мисалларга дөрес комментарийлар китерелә | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Барлыгы | 3 балл |

**17 биремне бәяләү критерийлары**

| Бәяләү критерийлары | Критерийга туры килү | Баллар |
|---|---|---|
| Лингвистик хатаны табу | Җавап юк яки хаталы җавап | 0 |
| | Лингвистик хата табыла | 1 |
| Табылган хата нигезендә лингвистик материалны аңлата белү | Лингвистик материал аңлатылмый яки хаталы аңлатыла | 0 |
| | Лингвистик материал дөрес һәм тулы итеп аңлатыла | 2 |
| Тема буенча биремнәр эшләгәндә, укучыларның типик хаталарын күрсәтә алу һәм аларны бетерү юлларын билгеләү | Укучыларның типик хаталары күрсәтелми яки дөрес күрсәтелми | 0 |
| | Укучыларның типик хаталары дөрес күрсәтелә, аларны бетерү юллары күрсәтелә | 2 |
| | Барлыгы | 5 балл |

**18 биремне бәяләү критерийлары**

| Бәяләү критерийлары | Критерийга туры килү | Баллар |
|---|---|---|
| Материалны аңлатуда проблемалы укыту методын куллану | Материалны аңлатуда проблемалы укыту методы кулланылмый яки дөрес кулланылмый. | 0 |
| | Материалны аңлатуда проблемалы укыту методы кулланыла. | 1 |
| Грамматиканы өйрәтү методикасының тиешле принципларын кулланылу | Грамматик материалны өйрәтү методикасының мөһим принциплары тиешле дәрәҗәдә үтәлми. | 0 |
| | Грамматик материалны өйрәтү методикасының мөһим принциплары тормышка ашырыла | 2 |
| Күрсәтмәлелек кулланылу | Бары тик вербаль күрсәтмәлелек кулланыла | 0 |
| | Визуаль һәм күрсәтмә материаллар кулланыла | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| Укучыларның индивидуаль һәм яшь үзенчәлекләренә игътибар ителү | Укучыларның индивидуаль һәм яшь үзенчәлекләренә игътибар ителми | 0 |
| | Грамматик материалны өйрәтү укучыларның индивидуаль һәм яшь үзенчәлекләрен истә тотып башкарыла | 0 |
| | | 2 |
| | Барлыгы | 7 балл |

**Татар әдәбиятыннан методик компетенцияләрне билгеләү өчен тәкъдим ителгән биремнәрнең бәяләү критерийлары**

**Бәяләү критерийлары 19-21**

| Бәяләү критерийлары | Критерийга туры килү | Баллар |
|---|---|---|
| 19 (1) Проблемалы укытуның ысул һәм формаларын аңлау, куллана белү | Дөрес җавап 3<br>1. Проблемалы сорау күп вариантлы җавап таләп итә.<br>2. Катлаулы була, аналитик эшчәнлек таләп итә.<br>3. Укучыларга аңлаешлы була.<br>4. Кызыксыну тудыра, җавап табарга этәрә.<br>5. Күләмле була, текстның тулы мәгънәсен үз эченә ала. | 3 |
| | Проблемалы сорауның барлык билгеләре табылмаса яки хаталы булса, яки нигезләнмәсә. | 2 |
| | Проблемалы сорауның билгеләре күрсәтелмәгән, җавап дөрес билгеләнмәгән. | 0 |
| 20 (2) Проблемалы укыту методының принципларын һәм аның төрле формалары һәм ысулларын белүне генә түгел, ә үз фикереңә ышандыру һәм аны дәллилли алу, дәрес кысаларында укучылар белән уртак тел | Дөрес җавап 3.<br>Методик һәм гомумпедагогик күзлектән караганда проблемалы укыту алымы белән дәресне дәвам итү өчен иң кулай дип саналган вариант. Килеп туган проблеманы ике төрле караштан чыгып, текстка мөнәсәбәтле дәлилләп бирү, укучыларны тарихи-мәдәни тәҗрибәсенә таяну. | 5 |

| | | |
|---|---|---|
| табу, элемтә урнаштыру, белем алуга уңай этәргеч бирә мотивация тудыра торган һөнәри эшчәнлекне тормышка ашыру осталыгын да күрсәтү | Дөрес җавап күрсәтелгән, ләкин дәлилләнмәгән. Шуның нәтиҗәсендә проблемалы укыту методының үзенчәлеге ачылмый/ Дөрес түгел җавапны күрсәтә, ләкин проблемалы ситуацияне аңлаганлыгын дәлилләп бирә. | 3 |
| | Дөрес җавап күрсәтелгән, дәлилләнмәгән. | 0 |
| 21 (3) Проблемалы укыту принцибына туры китереп дәресне планлаштыру һәм үткәрү, татар әдәбиятын укыту методикасын, эшчәнлекле якын килү принципларын белү һәм гомуми белем бирү программасына туры китереп уку-укыту процессын планлаштыру һәм гамәлгә ашыру күнекмәләрен һәм осталыгын күрсәтү | Текстка карата проблемалы сорау формалаштырылган һәм ул алда күрсәтелгән (19 (1)) таләпләргә туры килә, дәресне тиешле юнәлештә дәвам итәрлек проблемалы мәсьәлә куелган. | 7 |
| | Проблемалы сорау формалаштырылган, әмма дәлилләнмәгән. | 3 |
| | Проблемалы сорау формалаштырылмаган, проблемалы мәсьәлә куелмаган, дәлилләнмәгән. | 0 |
| | Барлыгы | 15 балл |